Челышева, Т. Тәүге шеф / Т. Челышева // Татарстан. – 2024. – №6 (389). – Б. 52-55.



# ТӘҮГЕ ШЕФ

## беренче эшкә урнашу хакында инде онытыла язган тарих

Татьяна Челышева

Югары уку йортларын хәзер тәмамлаучылар эшкә мәҗбүри бүленешнең нәрсә икәнен белми дә торгандыр инде. Бу хәл соңгы тапкыр үткән гасырда, 1992 елда булган иде. Ул чакта без – Казан университетының журналистика факультетын тәмамлаган дүрт кеше – мәҗбүри бүленеш буенча Яр Чаллыга, яңа гына ачылган телерадиотапшырулар редакциясенә килеп эләктек.

Анда безне телерадиокомпания директоры Рахман Галим улы Шәфигуллин үз туганнарына сөенгәндәй кочак җәеп каршы алды. Чаллы мэры белән таныштырды, шәһәр буйлап экскурсия үткәрде – һәм шуннан көн төнгә ялганды! Радиода да, телевидениедә дә, гомумән өлкәннәр тормышында да бернәрсә аңламаган кичәге студентларны кырларга, абруйлы түрәләр кабинетларына, туры эфирларга, рейдларга җибәрделәр... Тормыш кызыклы эш һәм мәгънә белән тулды – без беренче идек, без шәһәр телерадиотапшыруларын иң беренче булып оештырдык. Шуннан бирле 32 ел вакыт сиздерми генә үткән дә киткән икән!

### ТИЗ ҺӘМ ДӨРЕС

– Тиз һәм дөрес булсын! – дип өйрәтә башлады беренче эш көненнән үк үз корреспондентларын Рахман Галим улы. Һәм «Чаллы-ТВ» телекомпаниясе бүген дә шул сыйфатларына тугры.

– Шәһәр тормышы сюжетларга гаять бай ул, – дип тә ышандырды ул безне. Һәм без, микрофоннарыбызны һәм бик авыр «Репортер» аппаратын асып, йә вокзалга, йә дачаларга, йә КАМАЗ тулай торакларына юнәлә һәм һәркайда үз тапшыруларыбыз өчен кызыклы сюжетлар таба идек.

– Буш кайтмагыз! – дип куркыта иде ул безне. Һәм без юлыбызда очраган бөтен нәрсәдән кызык табарга өйрәндек. Мәсәлән, чегән таборында эни турында моңлы җыр сузуларын төшергән идек, искиткеч сюжет килеп чыкты – аңардан соң шәһәр халкы сукбайларга мәрхәмәтлерәк була башлады.

### ӨЧ ҮЛЧӘМЛЕ КРЕДО

– Безнең кредо өч үлчәмле, – дип кабатларга ярата иде Рахман Галим улы, әлеге фикерне безнең яшь башларга сеңдерергә тырышып. – Мәгълүмат бирү, мәгърифәт чәчү һәм күңел ачтыру. Әмма күңел ачтыру эчтәлексез һәм мәгънәсез түгел, ә тәрбияви булырга тиеш. Шуларны үтәсәгез, телевидениенең югары модасына тәңгәл киләчәксез.

Һәм без тәңгәл килергә тырыша идек – үз телевидениебезне булдырдык, ә телевидение безнең үзебезне камилләштерде.

### ГОМЕР ҮТӘ...

Хәзер инде ул вакыттагы яшь журналистларның узган гасырның 90 нчы елларындагы аклы-каралы фотолардагыдай ихлас күзләре

генә үзгәрми калган, җыерчыклар һәм тәҗрибә исә шактый өстәлгән... Безнең һәркайсыбызның үз гаиләсе, балалары, оныклары бар... Һәркайсыбыз төрле гаммәви мәгълүмат чараларында – газета, журнал, телевидение, радио редакцияләрендә эшләп чарланган... Хәзер инде үзебез дә, аксакаллардай, студентларны эшкә өйрәтәбез, ә инде алар бик юньсез булып тоела башласа, узган гасырдагы үзебезне, бик тә сабыр остазыбыз Рахман Галим улы Шәфигуллинны искә төшерәбез дә, «аксакалларча» тәкәбберлегебез шундук юкка чыга.

## ИКЕЛӘТӘ БУРЫЧ

Ул чакта Рахман Шәфигуллинга икеләтә бурыч йөкләнә – беренче шәһәр телерадиокомпаниясен оештыру һәм әлеге компаниядә эшләүчеләрнең үзләрен дә профессионалга әйләндерү. Ул әлеге максатларның икесенә дә ирешә. Телерадиокомпания белән без параллель үстек. Соңыннан тормышыбызда нинди генә хәлләр булмасын, анда эшләгән вакытыбыз хәтеребезгә мәңгегә уелды.

## «МИНЕМ ШӘХСИ БАТЫРЛЫГЫМ»

– Минем журналистикага юлым озын һәм катлаулы булды, – дип искә ала Рахман Галим улы.

Һәм, аның язмыш сикәлтәләре белән тулырак танышкан саен, үзебезгә ничек уңай туры килгәненә сөенергә генә кала: без шундук яхшы кешегә һәм яхшы шартларга килеп эләктек бит, бары тик иҗат ит кенә, башка барысын да – аппаратура юнәтүдән алып компаниянең статусын яклауга кадәр бөтен нәрсәне – җитәкчебез эшләгән булып чыга.

– Һәр кешенең тормышында аеруча илһамланып, рухланып, бөтен җанын биреп башкара торган эше була, – ди Рахман Галим улы. – Минем гомерем исә – Яр Чаллыда телерадиокомпания оештыруга бәйле иксез-чиксез мәшәкатьләр ул. Мактанып әйтүем түгел: үз вакыты өчен бу чын батырлык иде. Идеяне әйтүе генә җиңел бит аны, ә тормышка ашыра башлагач, меңнәрчә каршылык пәйда була! Әмма инде эшкә алынгансың икән – ничек тә утә! Тормыш шулай өйрәтә. Миңа һәр адымымда үземне аңлаучылар, ярдәм кулы сузучылар очрап торды, аларга рәхмәтем чиксез.

## «ВОРКУТАНЫ ОНЫТМАМ!»

– Шәхсән минем тарих ерак Воркутадан башланды, – дип исенә төшерә Рахман Галим улы. – 15 яшемдә абыем янына килдем. Техниклар мәктәбендә белем алдым, электр слесаре һөнәрен үзләштердем. Дүрт ел «Воркутауголь» комбинатында эшләдем.

Тулай торакта яшәдек. Кемнәр генә юк иде анда! Халык илнең төрле төбәкләреннән җыелган иде... Төрле милләт вәкилләре белән якыннан аралашу минем фикер-карашларыма, әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәтемә гаять зур йогынты ясады, бу чын тормыш мәктәбенә әйләнде. Гаепсез сөрелгәннәрнең ачы язмышы белән танышу журналист һөнәрен сайлауга этәргеч булды. Анда, «Молодежь Севера» газетасы каршындагы яшь хәбәрчеләр мәктәбендә, мин беренче журналистлык белемемне алдым. Мәкаләләрем кече ватанымда – «Татарстан яшьләре» газетасында, Балык Бистәсенең «Октябрь юлы» район газетасында, «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында басылды.

## МИНА КУЮЧЫДАН – ХӘБӘРЧЕГӘ

1969 елның көзендә Рахман Шәфигуллин Совет Армиясе сафларына чакырыла. Ерак Көнчыгышта 1113 нче аерым саперлар батальонында мина куючы, соңрак 192 нче мотоукчылар дивизиясенең «Во славу Родины» газетасында хәрби корреспондент була. Армиядән соң өлкән сержант Шәфигуллин Балык Бистәсенең «Октябрь юлы» район газетасына хәбәрче булып урнаша. Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә, аннары Ленинград югары партия мәктәбендә укый. «Леннаучфильм» киностудиясендә өч ел электрик булып эшләү дәверендә фильмнар төшерергә өйрәнә, монтаж серләренә төшенә. Укуын тәмамлагач, гаиләсе белән Яр Чаллыга кайта.

## ЧУЛМАНДАГЫ ЯШЬ КАЛА

– Бу Чулмандагы яшь каланың гөрләп үскән чагы иде. КАМАЗ үзе генә дә ни тора! – дип сокланып тасвирлый Рахман Галим улы яшьлеге шәһәрен. – Һәм без әлеге куәтле агымга килеп кушылдык. Автокалада илнең төрле төбәкләреннән килгән яшьләр күп иде.

Җиде ел «Якты юл» газетасында эшләгәннән соң мине Телевидение һәм радиотапшырулар буенча ТАССР дәүләт комитетының Яр Чаллыдагы корпункты җитәкчесе итеп куйдылар. Җирле яңалыклар республика матбугатында тиз арада һәм тиешенчә яктыртылсын өчен, КАМАЗ янәшәсендәге районнардан тәүлек буе кайтып кермәскә кирәк иде. Эфир вакыты чикле булганга, иң мөһим вакыйгаларны гына сайлап бирергә туры килде. Мин беркайчан да гайбәт эзләмәдем. Без гел позитив юнәлештә эшләдек...



## ЗАМАНАДАН КАЛЫШМЫЙЧА

Мин илдәге барлык тарихи чорларны һәм ТАССРдагы үзгәрешләр дәверен Чаллы телевидениесе белән бергә үттем. 1990 нчы еллардагы СССР таркалу сәясәте төбәкләрдә киеренкелек тудырды. Боларның барысын да халыкка аңлатырга кирәк иде. Ә ничек итеп?

Халыкка мәгълүмат җиткерү өчен газета-журналлар, радио һәм телевидение булу зарур. Дөресен әйткәндә, әлеге тармакта эшләүче белгечләр булмаганга, ул чакта телерадиокомпания оештыру хакында уйлаучы да юк иде.

Мин Яр Чаллыда телерадиокомпания оештыру белән актив шөгыльләнә башладым. Оештыру-техник чаралар, штат туплау, кирәкле аппаратура сатып алу планнары, чыгымнарны исәпләгән һәм башка документлар белән мин шәһәр җитәкчелеген таныштырдым, әмма алар тарафыннан кызыксыну сизмәдем.

Бары тик 1990 елның июлендә генә комиссия тәкъдиме буенча президиум утырышында «Чаллы төбәк эфир телевидениесен оештыру турында» карар кабул ителде.

1992 елның 15 апрелендә мин сессиянең көн тәртибенә «Яр Чаллы шәһәр советы һәм хакимиятенең телевидение һәм радио редакциясен оештыру турында» тәкъдим керттем. Мине хупладылар. Ул чакта илдә әле бер генә муниципаль телерадиокомпания дә юк иде.

Бу яңалык та, минем шәхси батырлыгым да булды. Әмма ниндидер карар нигезендә генә федераль каналда кушымта эшләтеп җибәрүгә кем рөхсәт бирер соң? Әлбәттә инде, Татарстан Президенты. Мин әлеге проблеманың уңай хәл ителәсенә ышандым. Моның кирәкле һәм игелекле эш булуын аңлауларына ихластан ышана идем.

Яр Чаллыдагы ретранслятор республикага буйсына. Казан Россия Элемтә министрлыгына буйсына. Мин Мәскәү – Казан юлын таптарга керештем.

Чаллы телерадиокомпаниясенең эше дә үткәргечле радиодан башланды. Безгә мэриянең беренче катындагы китапханә бинасын



бирделәр. Төзелеш кайнаганда, без яңалыкларны «Идел» магнитофонына яздырып, аларны 4 нче комплексның элемтә бүлегеннән халыкка җиткерә идек... Радиостудия монтажчылары булып Гүзәлия Сәлахова, Наил Ягъфәров, Земфира Бәширова эшләде. Зөлфия Хисмәтуллина, Әнисә Курамшина, Җәүдәт Әхмәтов һәм Земфира Хәсәнова диктор-журналист вазыйфаларын башкарды. Казан университетын яңа гына тәмамлаган журналистлар Лилия Сәлахиева, Татьяна Челышева, Фирүзә Харрасова килеп кушылды... Әкренләп яңа стационар магнитофоннар сатып алынды, тапшырулар турыдан-туры үзебездән китә башлады...

## БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР

Барысы да менә шулай башланды. Аннары исә без дә бөтен Чаллы халкы белән бергә туксанынчы еллар зәхмәтен кичердек – илдә тормыш бик катлауланды, автокалада вазгыять бик киеренкеләнде ул чакта. Кайчандыр КАМАЗ төзергә килүчеләр кире китә башлады. Завод-фабрикаларда, төзелеш мәйданчыкларында эш туктады. Хезмәт хакы он, сабын, аракы, төзелеш материаллары белән түләнде. Читтән товар ташучылар Чаллыны зур базарга әйләндерде. Вазгыять кискенләште.

Без радиода туры эфирлар үткәрдек. Шәһәр халкы сорауларына мэр һәм аның урынбасарлары өчәр сәгать буе җавап бирде. Көн саен! Бу эшкә милли җәмгыятьләр рәисләре җәлеп ителде – алар тынычлыкка өндәде. Радиотапшыруларга футбол буенча ил чемпионы – «КАМАЗ» командасы вәкилләре килгәндә, тыңлаучыларга аеруча ошый иде. Шуның өчен Николай Бех безгә биш репортер магнитофоны бүләк итте, бу безгә сюжетларны урамда да яздыру мөмкинлеген бирде. Балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрнең чыгышлары да радионың абруен арттырды. Безнең бәләкәй артистларның җырлавы йөрәкләрне җылыта иде. Чаллы радиосы каладагы 160 мең фатирда сөйләп торды.

Халык телетапшырулар да карасын өчен, VHS форматындагы видеокамера сатып алдык. «Чаллы-ТВ» дигән матур табличка пәйда булды. 1992 елның августында беренче тапшыруларны төшерү өчен студия булдырдык. Миңа исә эфирга федераль канал буенча чыгу мөмкинлеген табарга кирәк иде. Һәм мин республика радиотелевидение үзәгенә, ТР Министрлар Кабинетына чыгып киттем... Минем әлеге сәфәрләремне тасвирлау бик озакка сузылыр иде. Әмма төп нәтиҗә сөендерерлек – могҗиза булды!

## ЗУР ҖИҢҮ

Бу зур җиңү иде! Радиотелевидение тапшырулары үзәге (РТПЦ) белән җирле телерадиокомпания арасында Россиядә беренче һәм соңгы килешү! Безне Яр Чаллы халкы тәүлек буе котлады. Ул чакта телевидение бик абруйлы иде әле.

Безнең беренче тапшыруларыбыз: «Итоги. Йомгак», «Ачыктан-ачык сөйләшү. Откровенный

разговор», «Энҗе бөртекләре» («Жемчужины») балалар концерты...

Безнең эшебез белән танышырга теләүчеләр саны һаман арта барды. Мэр кунакларны Яр Чаллы белән таныштыруны телестудиядән башлый иде. Ә без аларга автокала турында видеофильмнар, артистларыбызның җырларын, Сабан туе яздырылган кассеталар бүләк итәбез...

Ул чакта «Яр Чаллы» телерадиокомпаниясендә минем мәктәпне үтүчеләр бүген Мәскәү, Казан, Яр Чаллыдагы гаммәви мәгълүмат чараларында эшләвен дәвам итә...

## СӨЕНЕЧ ХИСЕ

...Мин киләчәк, үсеш турында даими уйландым һәм гел алга бардым. Телевидение һәм радио өчен ешлыклар алырга кирәк иде. Бары тик яхшыга гына өметләнеп, тагын эшкә керештем.

Без алырга тиешле 51 нче канал самолет очышларына комачауламыйммы, хәрби оешмаларга зыян китермиме? Боларны ачыклауга алты ай кирәк булды. Аннары тагын бер проблема туды: тапшыргычларны кайда урнаштырырга? Тагын тикшерүләр, тикшеренүләр... Ниһаять, бер елдан соң Мәскәүдә ешлыклар бирә торган конкурс комиссиясе утырышы узды. Анда миңа Яр Чаллы өчен телевидениенең бик кирәк булуын дәлилләргә туры килде. 1995 елның маена бөтен эшләр төгәлләнде. Радио – 67,79 мГц, телевидение – 51ТВК.

Сөенечтән башым күккә тиде...

## ТӘГӘРМӘЧКӘ ТАЯК ТЫГУЧЫЛАР

Минем телевизион тормышымда тәгәрмәчкә таяк тыгучылар да, мине яраткан эшемнән аерырга теләүчеләр дә шактый күп очрады. Мин хәтта берара Менделеевск шәһәренә китеп тә эшләп алдым.

Әмма минем өчен иң мөһиме – яраткан эшем. «Сабыр иткән морадына җиткән» дигән мәкаль бар. Уйламый гамәл кылырга ярамый. Барысына да кул селтәп, ташлап китәсе килгән чаклар да булды, әмма үземә ышанган кешеләрне уңайсыз хәлгә куярга теләмичә, мин үземдә яңа көч таба һәм алга баруымны дәвам итә идем. Кайчан да булса тарих һәркемгә гадел бәя бирер, шуңлыктан начарлык эшләүчеләргә вакыт әрәм итеп тормаска кирәк.

## ЯҢА ИСКЕ ЭШ УРЫНЫ

Шулай килеп чыкты ки, миңа яңа иске эш урыныма кире кайтырга туры килде.

Яңа проектлар, тапшырулар пәйда булды. Аларның берсе кышкы бакчада төшерелә торган «Хәерле иртә, Чаллы! Доброе утро, Челны!» иде. «Ты не один» исемле ток-шоу үзенә күрә компаниянең визит карточкасына әйләнде. Ул без ташландык бинада җиһазландырган павильонда төшерелә иде. Бирелән, ягъни Яр Чаллыдан, Казан һәм Мәскәү белән туры эфирлар оештырылды.

Күп нәрсәне, җаным теләгәнне, үзем дә төшердем, мәсәлән, «Инзер буйларында» фильмын. «Тәрекләр илендә», «Латвиядә татарлар тормышы» фильм-тапшырулары да минеке. «Без тарихта эзлебез», «Яшь йөрәкләр», «Нам, молодым», «Талир тәңкә», «Гөлбакча», «Мәдәни сәхифә», «Тормыш мизгелләре», «Откровенный диалог», «Оперативная сводка» ул еллардагы иң уңышлы тапшырулар исәбендә йөри.




## «ЭШНЕ МЕНӘ ШУЛАЙ ОЕШТЫРЫРГА КИРӘК!»

Чаллы мэры Илдар Халиков безгә искергән аппаратураны яңартырга булышты. Мөмкинлекләр дә, сыйфат та шактый яхшырды.

2004 елда безгә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев килде һәм эшебезне Казан телеканаллары җитәкчеләренә үрнәк итеп куйды:

– Эшне менә шулай оештырырга кирәк! – диде ул.

1992 елның маенда «Күңел» радиосы эшли башлады. Әлфия Шәрипова җитәкчелегендә «Күңел» радиосы тәүлек буе сөйли торганга әйләнде, аны Интернет аша бөтен дөнья татарлары тыңлады, без ел саен «Иң яхшы татар радиосы» дигән мактаулы исемгә лаек булдык. Тәүлегенә биш сәгать буе нәкъ менә үзебез әзерләгән тапшырулар яңгырады.

## КЫЙБЛАДАН ТАЙПЫЛМЫЙЧА

Тамашачы әзер тапшыруны күргәнче, ул бик озын юл үтә. Аңа машина йөртүче, телеоператор, монтажлау остасы, журналист һәркайсы үз өлешен кертә... Эш циклы тулы бер чылбыр тәшкил итә. Вакыйга урынына вакытында барып җитмәсәң, чылбыр өзелә, яңалык искерә, тапшыру эфирга чыкмый кала...

2024 елның 2 июнендә миңа 75 яшь тулды. Дөресен әйтим, үз гомеремдә күпне күргән җитәкче буларак, мин үземне теләсә кайсы вакытта эштән җибәрү ихтималы булуын һәрвакыт белеп яшәдем һәм моңа әзер идем. Үземә лаеклы алмаш тәрбияләвемә горурланам. Телерадиокомпания, кыйбласыннан тайпылмыйча, үз халкы язмышына игътибарны гел арттырып, һәрчак алга барырга тиеш иде. Тарихта безгә бирелгән вакыт чикләнгән бит, шуңлыктан мин үзебезне һәр көнне, һәр минутта халык йөрәгенә иман, игелек, гаделлек нурларын сеңдерергә тиеш, дип санадым.